**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2959**
**19.06.2020**

Җир участогын арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 18 октябрендәге 6286 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 30 июнендәге 3380 номерлы, 2018 елның 3 октябрендәге 5781 номерлы, 2019 елның 5 апрелендәге 1747 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган җир участогын арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Гариза кергән көннән башлап утыз көн эчендә. | РФ Граждан кодексының 452 статьясы |

2) 3.5.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. ҖММИ башлыгы карар проектын карап тикшерә һәм:

1) баш тарту турында хатны имзалый һәм әлеге хатны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә;

2) килешү проектын килештерә һәм  килештерү өчен аны Башкарма комитетның хокук идарәсенә (алга таба - хокук идарәсе) җибәрә.

Срок - 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән баш тарту турында хат яисә килештерелгән һәм килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрелгән килешү проекты.»;

3) 3.5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3.5.5 - 3.5.7 пунктларны өстәргә:

«3.5.5. Хокук идарәсе килешү проектын карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен аны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, хокук идарәсе килешү проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр әзерли һәм әлеге кимчелекләрне төзәтү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Срок - 3 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән килешү проекты яисә ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән килешү проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр

3.5.6. Хокук идарәсе тарафыннан килешү проектындагы кимчелекләргә карата күрсәтмәләр җибәрелгән очракта, ҖММИ бүлеге белгече кимчелекләрне төзәтә һәм алга таба килештерү өчен, килешү проектын хокук идарәсенә җибәрә.

Срок - 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрелгән килешү проекты.

3.5.7. Хокук идарәсе төзәтелгән килешү проектын карап тикшерә, аны килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Срок - 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: хокук идарәсе тарафыннан килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән килешү проекты.»;

4) 2 нче кушымтаны әлеге карарга кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.


3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.


Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов


Башкарма комитетның
2020 елның 19 июнендәге
2959 номерлы карарына
кушымта

Җир участогын арендалауның гамәлдәге шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




ҖММИ бүлеге белгече ведомствоара хезмәттәшлек системасы аша документлар соратып алу кирәклеген билгели
Документлар соратып алырга кирәк
Юк
әйе
ҖММИ бүлеге белгече запрослар җибәрә
Мәгълүматлар бирү турында запрослар
ҖММИ бүлеге белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләрнең булуын тикшерә
Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре запросларны эшкәртәләр һәм мәгълүматларны (белешмәләрне) яки документлар (мәгълүматлар) булмау турында белдерү кәгазе җибәрәләр
Документлар (белешмәләр) яки документлар (белешмәләр) булмау турында белдерү кәгазе
Баш тарту өчен нигезләр
Юк
Бар
ҖММИ бүлеге белгече баш тарту турында хат әзерли
ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән баш тарту турында хат
ҖММИ бүлеге белгече килешү проектын әзерли һәм килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә
ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән килешү проекты
ҖММИ бүлеге башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм ҖММИ башлыгына җибәрә
Килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрелгән карар проекты
ҖММИ башлыгы карар проектын карап тикшерә:
1) баш тарту турында хатны имзалый һәм әлеге хатны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә;
2) килешү проектын килештерә һәм килештерү өчен аны Башкарма комитетның хокук идарәсенә (алга таба - Хокук идарәсе) җибәрә
Имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән баш тарту турында хат яисә килештерелгән һәм килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрелгән килешү проекты
Эш кәгазьләрен алып бару бүлеге белгече баш тарту турында хатны терки һәм аны гариза бирүчегә
Теркәлгән һәм гариза бирүчегә җибәрелгән баш тарту турында хат




Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова